ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына һәм «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 595-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.А. Якунин, К.Ә. Ногаев тарафыннан кертелгән «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына һәм «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 595-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 27 сентябре
№ 40-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Л.А. Якунин, К.А. Ногаев
тарафыннан кертелә

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына һәм «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында**

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы $2^1$ өлешенә (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8–9; 2016, № 1–2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 56 (I өлеш), «2020 – 2026 елларда» сүзләрен «2020 елдан» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 26 июлендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2024, № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) 2 статьяда:

а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Салым базасы кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә торган күчемсез мөлкәт объектларына карата, әлеге статьяның $3^1$ өлешендә күрсәтелгән күчемсез милек объектларыннан тыш, салым ставкасы 2 процент күләмендә билгеләнә.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 3[1] өлеш өстәргә:

«3[1]. Салым базасы кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә торган һәм һәрберсенең кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган күчемсез мөлкәт объектларына карата, халык саны 145 мең кешедән артык булган торак пунктлар территорияләрендә урнашкан гомуми мәйданы 2000 квадрат метрдан артык сәүдә үзәкләреннән (комплексларыннан) һәм алардагы урыннардан тыш, салым ставкасы 2025 елда 1,2 процент, 2026 елдан башлап 2,5 процент күләмендә билгеләнә.»;

2) 3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3[2]. Әлеге Законның 1[1] статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән күчемсез милек объектларына карата, әлеге Законның 2 статьясындагы 3[1] өлешендә күрсәтелгән халык саны 145 мең кешедән артык булган торак пунктлар территорияләрендә урнашкан гомуми мәйданы 2000 квадрат метрдан артык сәүдә үзәкләреннән (комплексларыннан) һәм алардагы урыннардан тыш, салым салымның исәпләнгән суммасыннан 60 процент күләмендә түләнә.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үзк өченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына һәм «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына һәм «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы (алга таба – 176-ФЗ номерлы Федераль закон), «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 8 августындагы 259-ФЗ номерлы (алга таба – 259-ФЗ номерлы Федераль закон) федераль законнар кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнде.

Хәзерге вакытта оешмаларның салым базасы кадастр бәясеннән чыгып исәпләнелә торган күчемсез милек объектларына карата салым Татарстан Республикасы территориясендә 2 процент күләмендә салына.

176-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе Салым кодексының 380 статьясына кертелгән үзгәрешләр нигезендә салым базасы кадастр бәясеннән чыгып исәпләнелә торган һәм кадастр бәясе 300 миллионнан артыграк булган күчемсез милек объектларына карата оешмалар мөлкәтенә салым 2,5 процент күләмендә билгеләнде. Закон проектында 2025 елга түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

– халык саны 145 мең кешедән артык булган торак пунктлар территорияләрендә урнашкан, һәрберсенең кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк, гомуми мәйданы 2000 квадрат метрдан зуррак булган сәүдә үзәкләре (комплекслары) һәм алардагы урыннар өчен салым ставкасын 2 процент күләмендә саклап калу;

– салым базасы кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә торган һәм һәрберсенең кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган калган күчемсез мөлкәт объектларына карата 1,2 процент күләмендәге киметелгән салым ставкасын билгеләү.

Гомуми файдаланудагы тимер юлларга һәм аларның аерылгысыз технологик өлеше булып торган корылмаларга карата хәзерге вакытта Россия Федерациясе Салым кодексының 380 статьясы нигезендә Россия Федерациясе субъекты законнары белән билгеләнә торган иң чик салым ставкасы куелган, ул 2020 – 2026 елларга 1,6 процент тәшкил итә. 259-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе Салым кодексының 380 статьясына югарыда телгән алынган объектларга карата 1,6 процент күләмендәге киметелгән иң чик салым ставкасы сроксыз билгеләнде.

Закон проекты Татарстан Республикасы законнарын гомуми файдаланудагы тимер юлларга һәм аларның аерылгысыз технологик өлеше булып торган корылмаларга карата 2020 елдан киметелгән салым ставкасын 1,6 процент күләмендә билгеләү өлешендә Россия Федерациясе Салым кодексы нормаларына туры китерүгә юнәлдерелгән.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»
Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына һәм
«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

## ИСЕМЛЕГЕ

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына һәм «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына һәм «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына һәм «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан акчалар төшеп калуга китерми.

Гомуми файдаланудагы тимер юлларга һәм аларның аерылгысыз технологик өлеше булып торган корылмаларга карата салым преференцияләре елны якынча 173,2 млн. сум тәшкил итәчәк.